| | | |
|---|---|---|
| «Рассмотрено»<br>Руководитель МО<br><br>Хузина Ф.Т. Хуз<br>Протокол № 1<br>от «23» 08 2017г. | «Согласовано»<br>Заместитель директора по УРВ ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»<br>_________ Яковлева М.В.<br><br>от «23» 08 2017г. | «Утверждаю»<br>Директор ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»<br>_________ Беспалова Т.В.<br>Приказ № 43<br>от «25» 08 2017г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

Шакировой Гульнары Расиховны, к.п.н.
Ф.И.О., категория

по татарской литературе, 5А класса
предмет, класс и т.п.

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
от «23» 08 2017г.

20 17 - 20 18 учебный год

# ПРАКТИЧЕСКОЙ ЧАСТИ УЧЕБНОЙ ПРОГРАММЫ

# ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

Класс: 5А

Учитель: Шакирова Г.Р.

Количество часов: всего - 70 ;  в неделю – 2.

Плановых контрольных работ: 2.

Административных контрольных работ:  1.

## Аңлатма язуы

Татар әдәбиятыннан 5 нче, 6 нчы, 7 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа дәүләт стандартларының федераль компонентына, гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнгән Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисматова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова тарафыннан язылган дәреслекләрдән (1 нче, 2 нче кисәк) укытуны күздә тота. Программа стандартның эчтәлеген җентекләп ачып бирә, стандарт таләп иткән күләмдә рус телле балаларга татар әдәбиятын укытуның гомуми юнәлешләрен билгели, предмет чаралары белән укучыларны тәрбияләү юлларын, аларның әдәби үсеш дәрәҗәсен билгели.

Күпмилләтле аудиториядә татар әдәбиятын укыту өчен төзелгән программа бербөтен документ булып тора, ул биш өлешне иңли: аңлатма язуы; укыту курсының эчтәлеге, укыту-тематик планы; укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр; курсның укыту-методик тәэмин ителеше өчен әдәбият исемлеге.

Әдәбият һәр яктан үскән, рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләү әһәмиятле урын алып тора. Урта белем бирү системасындагы татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүгә, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү һәм күнекмәләрне формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чараларын үзләштерү.

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядрога), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның **иҗтимагый** үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); **шәхси** үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерүгә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди караштa торган, тормыш авырлыкларын каршы торырлык шәхес тәрбияләү); **танып белү** эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып-белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле

укучы тәрбияләү); **коммуникатив** үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре дүрт блокка бүлеп каралды. Алар арасында **шәхси** УУГ – тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. Р**егулятив** уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. **Танып белү** гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. **Коммуникатив** УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

Универсаль уку гамәлләрен рус телле балаларга татар әдәбиятын укыту барышында куллану нәтиҗәсендә, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү юнәлеше көчәйде (мәсәлән: өй эше бирү – берничә вариантта). Бу вакытта укытучы эшчәнлегендә идарә итү алымнары көчәя.

Шул рәвешле, федераль дәүләт стандартларына таянып татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** да ачыкланды: туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

– Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

– татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

– татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халыкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

– татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

− татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, түбәндәге принциплар истә тотылырга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп баласына сүз сәнгатенең серләрен ачуда **эстетик принцип** (укытучының матурлыкны күрә алуы һәм башкаларне да күрергә өйрәтә алуы), **эзлеклелек** (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), **әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү** (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни **психологик принцип** (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү) ярдәмгә килә. Аерым игътибар **коммуникативлык принцибына** бирелә. Бу принципның өстен чыгуы рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәрен сорауларга нигезләнеп сөйли алуы, үз фикерләрен ачык әйтә алуы, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәрне кабул итү һәм әдәби үсеш  үзенчәлекләрен исәпкә алып, **дифференциацияләү** (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм **интеграцияләү** (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алынган теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

# 5 НЧЕ СЫЙНЫФ

## I бүлек

Төп мәктәп уку-укыту системасында 5 нче сыйныф әһәмиятле урын алып тора. Бу сыйныф балаларының яшь һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән УМК үз эченә дәреслекне, укучы өчен мөстәкыйль эш дәфтәрен, укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Дәреслек ике кисәктән тора. Укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләп бару өчен, һәр кисәк тә дүртәр модульгә бүлеп төзелгән. Һәр модуль бөтен кисәкнең өлешләрен хәтерләтә. Модульгә салынган мәгълүмат та, дәреслек үзе дә хронологик нигезгә корыла. Шул ук вакытта модульләр эчендә тематик-хронологик принцип та саклана.

Һәр модуль укучыларның әдәби үсеш дәрәҗәсен үстерүне дә, эрудициясен киңәйтүне дә, әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләп баруны да, теоретик төшенчәләрне үзләштерүне дә, сорау-биремнәрне үтәгәндә файдалана алуны да күздә тотып урнаштырылган. Дәреслектә модульләр арасындагы бәйләнешләр сорау-биремнәр һәм контроль тестлар аша гамәлгә куела. Шулай итеп, дәреслекне әдәби-теоретик төшенчәләр сүзлекчәсе, фразеологик сүзлекчә кебек белешмәләр төгәлләп куя.

Дәреслеккә салынган әдәби әсәрләрнең нигезен “Үрнәк программа”да күрсәтелгән (төзүчеләре: *Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова)* әдәби әсәрләр минимумы (7 әсәр) тәшкил итә. Алар түбәндәгеләр:

К. Насыйри, “Патша белән карт”;

Г. Тукай, “Су анасы”;

М. Җәлил, “Алтынчәч” (либреттодан өзек);

Ф. Кәрим, “Кыр казы”;

Ф. Хөсни, “Чыбыркы” (хикәясеннән өзек);

М. Әгъләм, “Матурлык минем белән”;

Н. Дәүли, “Бәхет кайда була?”

## II бүлек

## 5 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:

– әдәби әсәрләрне сүзләрен дөрес әйтеп йөгерек уку;
– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
– әдәби − теоретик төшенчәләрне рус әдәбият белеме белән тәңгәлләштерү;
– татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
– 8 − 10 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
– 3 − 4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗатын турында мәгълүматлы булу;
– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;
– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;
– төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар булу, берничә мисал китерә белү;
– 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;
– мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;
– төрле авторларның 2 − 3 шигырен яттан сөйли белү;
– сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;
– төрле темаларга проект эше яклау;
– әдәби әсәргә тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## III бүлек

### Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр:

Дәрдемәнд, “Кил, өйрән...”
Ф.Кәрим, “Сөйләр сүзләр бик күп алар...”
Р.Фәйзуллин, “Табигать кочагында”

### Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләр

(укытучы сайлавы буенча):

Башмак (татар халык әкияте)
Төлке белән Алёнушка (рус халык әкияте)
Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми? (башкорт халык әкияте)
Куркак юлдаш (татар халык әкияте)
Каюм Насыйри. Күләгә
Фәнис Яруллин. Хәтерсез күке
Владимир Даль. Кар кызы
Ганс Христиан Андерсен. Борчак өстендәге принцесса
Рудольф Эрих Распе. Сигез аяклы куян
Тукай-Апуш. Рабит Батулладан
Илдус. Ибраһим Газидан
Мөнирә Булатова
Фатих Кәрим. Ватаным өчен
Мәңгелек хәтер. Лев Кассильдан
Сугышчан бурыч. Фаил Шәфигуллиннан
Оҗмах балалары. Мәдинә Маликовадан
Көнбагыш чәчәге. Фоат Садриевтан
Әхмәт Рәшитов. Кояшлы ил — бәхет иле
Туган көн. Мәгъсүм Хуҗиннан

Нури Арсланов. Ринат авылда
Чәчәк нигә боекты? Габделхәй Сабитовтан
Борис Вайнер. Искиткеч китап
Шәүкәт Галиев.Ул кем? Әлләкем. Мәрзия мәсьәләсе

# IV бүлек

## 5 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| Дә-рес № | Дәрес темасы | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | метапредмет | предмет | шәхси | |
| 1 | Акыллы сүзгә ни җитә! Белмәгәнгә — әкият, белгәнгә — чын. | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру. Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру, әкият турында белем бирү. | Халык авыз иҗатын тарих белән бәйләп өйрәнү. Татар һәм рус әкиятләрен чагыштырып өйрәнү. | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау. Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау, әкият турында белем алу. | Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. «Әкиятләр» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. |
| 2 | Акыллы сүзгә ни җитә! Белмәгәнгә — әкият, белгәнгә — чын. | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру. Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру, әкият турында белем бирү. | Халык авыз иҗатын тарих белән бәйләп өйрәнү. Татар һәм рус әкиятләрен чагыштырып өйрәнү. | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау. Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау, әкият турында белем алу. | Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. «Әкиятләр» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Акыллы сүзгә ни җитә! Белмәгәнгә — әкият, белгәнгә — чын. | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру. Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру, әкият турында белем бирү. | Халык авыз иҗатын тарих белән бәйләп өйрәнү. Татар һәм рус әкиятләрен чагыштырып өйрәнү. | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау. Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау, әкият турында белем алу. | Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. Укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү. | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. «Әкиятләр» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. |
| 4 — 5 — 6 | Яхшылыкка каршы яхшылык. | «Ак бүре» әкияте белән танышу. Әкиятне уку. | Укыган буенча кирәкле мәгълүматны аерып ала белү. | «Ак бүре» әкиятен укып үзләштерү, аның кайсы төргә керүен билгеләү. | Балаларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, яхшылык эшләргә өндәү. | Әкиятне укып чыгу һәм тирән сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. |
| 7 — 8 | Булма син төлке, булырсың көлке. | «Абзар ясау-чы Төлке» татар халык  әкиятен өйрәнү. | Уңай һәм тискәре сыйфатларны билгели алу, чагыштырып нәтиҗә ясый белү. | «Абзар ясаучы Төлке» татар халык әкиятен өйрәнү. | Балаларда намуслылык, гаделлек сыйфатларына карата хөрмәт тәрбияләү. | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү. |
| 9 — 10 | Ана дигән хәзинә. Борын-борын заманда... | «Өч кыз» татар халык әкиятен өйрәнү, әчтәлеген үзләштерү. | Кирәкле мәгълүматны аерып алып, чагыштырып нәтиҗә ясый белү. | «Өч кыз» татар халык әкиятен өйрәнү, әчтәлеген үзләштерү, кызларга сыйфатнамә бирү. | Балаларда ата-анага, олыларга карата хөрмәт тәрбияләү. | Дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр эшләп, әкиятнең әчтәлегенә төшенү, геройларга бәяләмә бирү. |
| | | Халык әкиятләрен гомумиләш-тереп кабатлау, аларның төрләргә бүленешен искә төшерү. | Халык иҗатының бай мирасын өйрәнү, әхлак һәм эстетик тәрбия бирү. | Әкият жанрын кабатлау, аның төрләргә бүленешенең принципларын истә калдыру. | Укучыларда әкиятләргә мәхәббәт тәрбияләү, сөйләм культурасын үстерү. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү. |
| 11 — 12 | Яшәгән, ди, булган, ди... | К.Насыйри-ның тормыш юлы һәм иҗаты ту-<br>рында белемнәрне үзләштерү, «Патша белән карт» әсәрен өйрәнү; «автор әкияте», | Билгеле күрсәтмә нигезендә эшли белү, нәтиҗә ясау. | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү,  «Патша белән карт» әкиятен өйрәнү;<br>«автор әкияте», | Балаларда кешелек-лелек, намуслылык, гаделлек сыйфатларына карата хөрмәт тәрбияләү. | Әңгәмә, сәнгатьле уку. Бирелгән билгеләмәләргә нигезләнеп, нәтиҗә ясау. Үз фикереңне әйтә белергә өйрәнү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «әдәби герой» төшенчәләрен аңлату. | | «әдәби герой» төшенчәләрен аңлату. | | |
| 13<br>—<br>14<br>—<br>15 | Юк дип әйтмә, бардыр ул... | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Су анасы» әкиятен өйрәнү; «шигъри әсәр», «әкият-поэма» төшенчәлә-рен аңлату. | Рус әдәбияты белән чагыштырып, мифик образлар сурәтләнгән әсәрләрне анализлау. | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Су анасы» әкиятен өйрәнү; «шигъри әсәр», «әкият-поэма» төшенчәләрен аңлату. | Укучыларга, әсәрдән чыгып, кеше әйберен сораусыз алырга ярамаганлыкны аңлату. | Әкиятне уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, әкият-поэмада әкияткә хас сыйфатларны табу. |
| 16 | Б.Әлменов. «Су анасы» картинасы. | Рәссам Б.Әлменов-ның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда рәсем сәнгате аша эстетик зәвык тәрбияләү. | Рәссам Б.Әлменовның тормыш юлы һәм иҗаты белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу; рәсем сәнгате турында сөйләү. | Балаларда табигатьнең матурлыгына соклану, рәсем сәнгатенә карата кызыксыну уяту. | Рәсемне аңлау, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләтү, нәтиҗә ясау. |
| 17<br>—<br>18 | Әкиятче бездә кунакта. | Т.Миңнул-линның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Гафият турында әкият» әсәрен өйрәнү. | Укучыларда театр сәнгате аша әкиятләр укуга кызыксыну уяту. | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Гафият турында әкият» әсәрен өйрәнү, «әкият-пьеса», «драма әсәре» төшенчәсен аңлату. | Балаларда үз-үзләренә карата җаваплылык, олыларны хөрмәт итү хисе тәрбияләү. | Әкият-пьесаны сәнгатьле итеп уку, аңлаганны сораулар ярдәмендә тикшерү, анализлау. |
| 19<br>—<br>20 | Әкияттә кунакта. | «Әкият» курчак театры белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү. | «Әкият» курчак театры турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Балаларда театр сәнгатенә карата кызыксыну, ихтирам уяту. | Яңа материал белән танышу, укытучының кереш сүзе, укылган текст буенча фикер алышу. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 21<br>—<br>22<br>—<br>23<br>—<br>24<br>—<br>25<br>—<br>26 | Әкият тә түгел, чын да түгел...<br>Кабатлау :<br>Хыял дөньясын-да. | А.Тимергалин-нең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, «Сәер планетада» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү;<br>Әкият һәм фантастика темаларын гомумиләш-тереп кабат-лау.<br>**Контроль эш.** | Укучыларда галәмне өйрәнүгә, астрономия фәненә кызыксыну уяту.<br>Укыганны гомумиләш-терә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | А.Тимергалин-нең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу,<br>«Сәер планетада» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү.<br>Әкият жанрын фантастикадан аеру күнекмәләрен булдыру. | Әсәрдәге вакыйгалар аша балаларда җаваплылык хисләре тәрбияләү.<br>Укучыларда әкиятләргә мәхәббәт тәрбияләү, сөйләм культурасын үстерү. | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау.<br>Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. |
| 27<br>—<br>28 | Белем — бәхет ачкычы.<br>Белем укудан башлана. | «Белемгә омтылу» белешмәсен уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлы булу турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү.<br>«Мөхәммә-дия» мәдрәсәсе турында уку; татар халкы-ның белемле булуы турын-да сөйләшү, белем алу, укымышлылык турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү. | Татар әдәбиятының үсешен тарих белән бәйләп өйрәнү.<br>Укыган текстны аңлап, тарихи күзәтү ясый белү. | «Белемгә омтылу» белешмәсен уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, «мәгърифәт-челек хәрәкәте» төшенчәсен аңлату.<br>«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү. | Балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү.<br><br>Балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү. | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү.<br>Төрле биремнәр эшләү.<br>Китаптагы текст белән танышу, уку, укытучының истәлекләр белән таныштыруы. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | Укытучылар мәктәбе.<br>Казан университеты. | Казанның Татар укытучылар мәктәбе турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлы булу турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү.<br>Казан университеты турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлылык турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү. | Укучыларда белем алуга, укымышлы булуга кызыксыну уяту.<br>Казан университеты тарихы белән таныштыру. | Казанның Татар укытучылар мәктәбе турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү.<br>Казан университеты турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү. | Балаларда белемгә омтылыш, укытучы һөнәренә ихтирам тәрбияләү.<br>Балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү. | Тема буенча укытучының кереш сүзе, текстны укып, әңгәмә оештыру.<br>Текст җөмләләрен кыс-картып әйтү, анализ ясау. |
| 30—31 | Галим кеше хөрмәткә лаек! | Г.Исхакый-ның «Мөгал-лим» әсәрен уку, эчтәлек-не үзләште-рү; укучыларда белемгә омтылыш уяту, укытучы хезмәтенә ихтирам тәрбияләү. | Укыган әсәрне бүгенге көн, көндәлек тормыш белән бәйләнештә күзаллый белү. | Г.Исхакыйның «Мөгаллим» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү. | Балаларда укытучы хезмәтенә ихтирам тәрбияләү. | Әсәрне аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 32 | Кил, өйрән… Укысаң – белерсең... | Дәрдемәнд-нең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Кил, өй-рән…» шигы-рен өйрәнү. Мәгърифәт-челек чоры әдәбия-тын кабатлау. Тест. | Шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысулларын белү. Укыганны гомумиләш-терә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгъ-лүматны аерып ала белү. | Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Кил, өйрән…» шигырен өйрәнү. Мәгърифәтче-лек чоры һәм әдәбияты белән танышуны гомумиләште-реп кабатлау. | Укучыларда телләр өйрәнүгә кызыксыну тудыру. Балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү. | Текстның эчтәлеген аңлап, үз фикереңне әйтә белү. Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. |
| 33 – 34 | Исемдә калганнар. | Г.Тукайның «Исемдә кал-ганнар» авто-биографик әсәре аша укучыларны аның балача-гы белән таныштыру; эти-әниләргә карата ихтирам тәрбияләү. | Шагыйрьнең авыр тормышта үсүен укучыларга аңлату. | Г.Тукайның «Исемдә калганнар» автобиографик әсәре аша укучыларны аның балачагы белән таныштыру. | Укучыларда эти-әниләргә карата ихтирам тәрбияләү. | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү. |
| 35 — 36 | Бөек Тукай һәм Бәләкәй Апуш. | Рәссам Х.Казаков-ның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә мате-риаллар аша танышу. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү. | Рәссам Х.Казаковның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу; рәсем сәнгате турында сөйләү. | Балаларда Г.Тукайның балачагына, рәсем сәнгатенә карата кызыксыну уяту. | Рәсемне аңлау, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләтү, нәтиҗә ясау. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 37 | Музейларда — хәтер.<br>Кабатлау :<br>Ямьле балачак. | Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү. Укыганны гомумиләш-терә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгъ-лүматны аерып ала белү. | Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу.<br>Укыганнарны гомумиләш-тереп кабатлау. | Балаларда Г.Тукай белән бәйле истәлекләргә карата кызыксыну, ихтирам уяту. Балаларда һәр мизгелнең кадерен белеп яшәүне тәрбияләү. | Тукай музее белән танышу. Видео, презентацияләр карау. Укыганнарны искә төшереп, гомумиләштереп кабатлау. Тексттан мисаллар китереп, теорияне искә төшерү. Белемнәрне тикшерү. |
| 38 | «Салават күпере» журналы.<br>Проект-дәрес «Салават күпере — дуслык күпере». | «Салават күпере» журналы турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү. Командада эшләргә, проект эше башкарырга өйрәнү. | «Салават күпере» журналы белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу.<br>«Салават күпере» журналы белән таныштыру, сөйләм телен үстерү. | Балаларда «Салават күпере» журналына карата кызыксыну уяту.<br>Татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру, үзара сөйләшеп, күмәк эшләргә өйрәтү. | Хикәя төзү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>Командалап эшләү, рубрикаларны укып, фикер алышу, булган материалдан кирәклесен сайлап алып эшкәртү, эшне аудиториягә тәкъдим итү. |
| 39 – 40 — 41 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» | Гадел Кутуй-ның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Рөстәм маҗара-лары» әсәрен өйрәнү; «чагыштыру» төшенчәсен аңлату. | Укучыларга әсәрнең фантастик маҗара стилендә бирелешен аңлату. | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Рөстәм маҗаралары» әсәрен өйрәнү; «чагыштыру» төшенчәсен аңлату. | Укучыларны тормышта уяу булырга, әти-әни сүзен тыңларга, олыларны хөрмәт итәргә өйрәтү. | Фантастик хикәяләүне аңлап, әсәрне аңлау, сугыш чоры, партизаннар турында белү, сүзләрне тәрҗемә итеп, мәгънәләренә төшенү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 42 | Мин сине шундый сагындым... Гомере анық моңлы бер җыр иде... | Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Сагыну» шигырен өйрәнү, язучының патриот шагыйрь икәнлеген, каһарман сугышчы булуын аңлату. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча белемнә-рен нығыту, «Соңгы җыр» шигырен өйрәнү, сугышчылар-ның батырлыгына ихтирам, фашизм-га карата тарих аша нәфрәт хисе тәрбияләү. | Балаларга язучының патриот шагыйрь икәнлеген, каһарман сугышчы булуын аңлату. Сугышчылар-ның батырлыгына ихтирам, фашизмга карата нәфрәт хисе тәрбия-ләү. | Муса Җәлилнең «Сагыну» шигырен өйрәнү, язучының патриот шагыйрь икәнлеген, каһарман сугышчы булуын аңлату. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча белемнәрне нығыту, «Соңгы җыр» шигырен өйрәнү. | Балаларда азатлык өчен көрәшүче сугышчыларга карата ихтирам тәрбияләү.<br><br>Балаларга язучының үлем куркынычы астында да туган илгә, халкыбызга туг-рылык саклап калган шагыйрь икәнлеген аңлату. | Язучы иҗаты белән танышу, әсәрне укып, укытучы җитәкчелегендә бергәләп анализлау, нәтиҗә ясау. Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 43 | «Алтын-чәч». Опера ничек туа? Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры. | Муса Җәлилнең «Алтынчәч» әсәрен өйрәнү, «опера», «либретто» төшенчәләрен аңлату, балаларда татар халкының тарихына карата кызыксыну уяту. Композитор Нәҗип Җиһановның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү; М.Җәлилнең татар театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеген аңлату. Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү. Театр, балет, опера сәнгате белән әдәбиятны бәйләп өйрәнү. | Муса Җәлилнең «Алтынчәч» әсәрен өйрәнү. Композитор Нәҗип Җиһановның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда татар халкының тарихына карата кызыксыну уяту. Балаларда татар музыкасына карата кызыксыну уяту. Балаларда татар музыкасына карата кызыксыну, ихтирам уяту. | Эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку. Тема белән кызыксынып, уйны ачык итеп әйтү. Эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр, чылбыр буенча уку, диалогик сөйләм үстерү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 44 | Кыр казы<br>Сөйләр сүзләр бик күп алар... | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, Фатих Кәримнең «Кыр казы» шигырен өйрәнү.<br>«Сөйләр сүзләр бик күп алар» шигырен сәнгатьле итеп уку; туган илгә карата мәхәббәт тәрбияләү. | Сугыш кырларында илебезнең азатлыгы өчен кан коелуның мәгънәсен укучыларга аңлату.<br>Шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысулларын өйрәнү. | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, Фатих Кәримнең «Кыр казы» шигырен өйрәнү.<br>Фатих Кәрим иҗатын өйрәнүне дәвам итү, «Сөйләр сүзләр бик күп алар» шигырен сәнгатьле итеп уку. | Укучыларда азатлык өчен көрәшкән сугышчыларга карата ихтирам тәрбияләү.<br>Укучыларда азатлык өчен көрәшкән сугышчыларга карата ихтирам тәрбияләү. | Сәнгатьле уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр аша лирик әсәрне анализлау.<br>Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 45 | Аталы-уллы солдатлар. Кабатлау: Сугыш кайтавазы. | Ш.Галиевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, шагыйрьнең «Аталы-уллы солдатлар» балладасын өйрәнү; «баллада» төшенчәсен аңлату. Бу бүлектә өйрәнелгән материалны гомумиләш-тереп кабатлау, белемнәрне тикшерү. **Контроль эш.** | Укыганны гомумиләш-терә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | Ш.Галиевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, шагыйрьнең «Аталы-уллы солдатлар» балладасын өйрәнү; «баллада» төшенчәсен аңлау. Укыганнарны гомумиләш-тереп кабатлау. | Укучыларда илебез халкының фашистларга каршы гомерләрен дә кызганмыйча көрәш алып барулары турында фикер алышу, ветераннарга багышланган истәлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. Укучылар белән тынычлык өчен көрәш алып баручылар турында фикер алышу, аларга багышланган истәлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. | Уку, рәсемнәр буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү, фикерне ачу. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү. |
| 46 | Дәрес-проект «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый...» | Сугыш елларының әдәбиятта сурәтләнүен аңлау, аны бүгенге күзлектән тасвирлау. | Команда белән эшләү күнекмәләрен булдыру. | Әдәбиятта сугыш сурәтләнешен бәяләү. | Укучыларда көрәшчеләргә ихтирам, үз эшең белән горурлану хисләрен үстерү, дөрес бәяләү күнекмәләре булдыру. | Командалап эшләү, китапчыклар, буклетлар яки плакатлар ясау, аларны тәкъдим итү. |
| 47—48—49 | «Бәхет кайда була?» Туган җирдә минем бәхетем. | Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Бәхет кайда була?» шигырен өйрәнү. | Укучыларга хезмәтнең, тырышлык-ның бәхет чыганагы икәнлеген аңлату. Укучыларга әдәби әсәр аша туган илнең кадерен төшендерү. | Шагыйрь Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Бәхет кайда була?» шигырен өйрәнү. «Мин җирдә калам» әсәрен өйрәнү, шигырьне сәнгатьле итеп уку. | Балаларда хезмәткә, хезмәт кешесенә ихтирам тәрбияләү. | Язучы иҗатына күзәтү ясау, әсәрен укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү. |
| | | «Мин җирдә калам» әсәрен өйрәнү, шигырьне сәнгатьле итеп уку; бәхет, хезмәт турында фикер алышу, хезмәткә ихтирам тәрбияләү. | | | Балаларда туган якка, табигатькә ихтирам тәрбияләү. | Уку, сораулар, биремнәр ярдәмендә эчтәлеген аңлау, әсәр буенча фикер алышу. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 50 — 51 — 52 | Минем холкым — минем язмышым. | Фатих Хөснинең «Чыбыркы» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү; сюжет элементларын өйрәнү; укучыларда белемгә омтылыш уяту, җаваплылык хисләре тәрбияләү. | Укылганнардан нәтиҗә ясап, тормышта куллану. | Фатих Хөснинең «Чыбыркы» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү, сюжет элементларын өйрәнү. | Әсәрдәге вакыйгалар аша балаларда җаваплылык хисләре тәрбияләү. | Әсәрне өлешләргә бүлү. Эчтәлекнең идеясен таба белү. Исем табу — тема — идея — эчтәлек бәйләнешләрен табу, анализлау. |
| 53 — 54 | Кабатлау дәресе. Кояшлы ил — бәхет иле. | Өйрәнелгән материалны гомумиләш-тереп кабатлау, белемнәрне тикшерү. «Кояшлы ил — бәхет иле» шигырен укып, җырын өйрәнү. | Укыганны гомумиләш-терә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгъ-лүматны аерып ала белү. | Укыганнарны гомумиләш-тереп кабатлау. | Балаларда бәхетнең кадерен белеп яшәү хисләрен тәрбияләү. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, җыр өйрәнү, белемнәрне тикшерү. |
| 55 — 56 — 57 | Табигать кочагында. | Равил Фәйзуллин-ның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Табигать кочагында» әсәрен өйрәнү. | Укучыларга экологик тәрбия бирү. | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Табигать кочагында» әсәрен өйрәнү. | Балаларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту. | Уку, әңгәмә, биремнәрне үтәү, рәсем ясау. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 58<br>—<br>59<br>—<br>60 | Матурлык минем белән. Җир-ана, кояш һәм башкалар. Җир-ана-быз —рәсем-нәрдә. | Мөдәррис Әгъләмнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Матурлык минем белән» .<br>«Җир-ана, кояш һәм башкалар» әсәрләрен өйрәнү, «баллада» төшенчәсен кабатлау. Рәссам И.И.Шиш-кинның тормыш юлы һәм иҗаты белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү.<br>Экологик тәрбия бирү.<br>Рәсем сәнгатенә карата кызыксыну уяту. | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу; «Матурлык минем белән» «Җир-ана, кояш һәм башкалар» әсәрләрен өйрәнү, «баллада» төшенчәсен кабатлау.<br>Рәссам И.И. Шишкин-ның тормыш юлы һәм иҗаты белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу; рәсем сәнгате турында сөйләү. | Укучыларда табигатьнең матурлыгына соклану, туган илгә карата мәхәббәт тәрбияләү.<br>Укучыларга хезмәтнең бәхет, шатлык, хөрмәт чыганагы икәнлеген төшендерү.<br>Балаларда табигатьнең матурлыгына соклану, рәсем сәнгатенә карата кызыксыну уяту. | Уку, сорауларга җавап бирү. Хикәя буенча фикер алышу.<br>Сүзлек өстендә эш, эчтәлек буенча фикер алышу.<br>Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 61<br>—<br>62 | Кабатлау дәресе.<br>Туган илем — иркә гөлем.<br>Белем — нур, белмәү — хур. | Өйрәнелгән материалны гомумиләш-тереп кабатлау, белемнәрне тикшерү.<br>Л.Леронның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Пирамида» әсәрен өйрәнү.<br>**Контроль эш.** | Укыганны гомумиләш-терә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.<br>Укучыларда укуга, фәннәргә карата кызыксыну уяту. | Укыганнарны гомумиләш-тереп кабатлау.<br>Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Пирамида» әсәрен өйрәнү, «юмор» төшенчәсен аңлату. | Табигатькә мәхәббәт тәрбияләү.<br>Балаларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, җаваплылык, игътибарлылык хисе тәрбияләү. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү.<br>Текстны уку, сүзлек эше, рәсем буенча сөйләшү, биремнәр эшләү, сорауларга җавап бирү. |
| 63<br>—<br>64<br>—<br>65<br>—<br>66 | Беренче хисләр... | А.Гыйма-диевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Зөлфия +...мин» әсәрен өйрәнү. | Әдәби әсәрләрдә укыганнардан нәтиҗә ясап, тормышта куллана белү. | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Зөлфия +...мин» әсәрен өйрәнү. | Укучыларда бер-берләренә карата ихтирам, дуслык хисләре тәрбияләү, әдәплелек кагыйдәләрен төшендерү. | Дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәрне эшләп, хикәянең эчтәлегенә төшенү, геройларга бәяләмә бирү. |
| 67<br>—<br>68<br>—<br>69<br>—<br>70 | Үткән темаларны кабатлау. Ел дәвамында үткәннәргә йомгак ясау. Йомгаклау дәресе | Язучыларның әсәрләрен кабатлау. Тест | Әдәби әсәрләрдә укыганнардан нәтиҗә ясап, тормышта куллана белү. | | Укучыларда бер-берләренә карата ихтирам, дуслык хисләре тәрбияләү, әдәплелек кагыйдәләрен төшендерү. | Дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәрне эшләргә<br>Укучыларның докладларын тыңлау |